**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ТЮЛЯЧИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **с. Тюлячи** **КАРАР**

**«31» январь 2026ел** **№ 10**

Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районында 2026 елга җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр бәясен раслау турында

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль закон, «Күмү һәм җирләү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2026 елның 31 гыйнварындагы 30 номерлы «2026 елда түләүләр, пособиеләр һәм компенсацияләр индексациясе коэффициентын раслау турында» карары, «Җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләрен (вәкаләтләрнең бер өлешен) Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы җирле үзидарә органнарына тапшыру турында» Теләче муниципаль районы авыл җирлекләре Советларының 13 карары, «Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы составына керүче җирлекләрнең аерым мәсьәләләрен хәл итү вәкаләтләрен (вәкаләтләрнең бер өлешен) кабул итү турында» Теләче муниципаль районы Советының 2023 елның 26 июнендәге 195 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 2026 елның 28 гыйнварындагы ЛХ-28/280/2026 номерлы хатын карап, Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1.2026 елның 1 февраленнән билгеләргә һәм гамәлгә кертергә:

- 1, 2 номерлы кушымталар нигезендә, Теләче муниципаль районында җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр бәясен;

- 3 номерлы кушымта нигезендә, Теләче муниципаль районында, авыл җирлекләрен дә кертеп, җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр бәясен

3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге адрес буенча бастырырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Теләче муниципаль районының рәсми сайтында Интернет челтәрендә урнаштырырга: http://tulachi.tatarstan.ru.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары – территориаль үсеш бүлеге башлыгы Р.В. Нигъмәтҗановка йөкләргә.

Җитәкче И.Х. Хәмидуллин

Татарстан Республикасы
Теләче муниципаль районы
Башкарма комитетының
«30» 01 2026 ел № 10
карарына 1 номерлы кушымта

Теләче муниципаль районында җирләү хезмәтләренең гарантияләнгән исемлеге бәясе 01.02.2026 ел башлап

| Хезмәт күрсәтү атамасы | Хезмәтләр бәясе (сумнарда) |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 188,30 |
| 2. Табутны һәм җирләү өчен кирәкле башка әйберләрне бирү һәм китерү. | 4030,24 |
| 3. Мәрхүмнең гәүдәсен (калдыкларын) зиратка күчерү | 1151,65 |
| 4. Җирләү (каберләрне казу һәм күмү) | 4308,44 |
| **БАРЛЫГЫ:** | **9678,63** |

Татарстан Республикасы
Теләче муниципаль районы
Башкарма комитетының
«31» 01 2026 ел № 10
карарына 2 номерлы кушымта

Теләче муниципаль районында җирләү хезмәтләренең гарантияләнгән исемлеге бәясе 01.02.2026 ел башлап

| Хезмәт күрсәтү атамасы | Хезмәтләр бәясе (сум.) |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 188,30 |
| 2. Кәфенләү | 318,38 |
| 3. Табутны һәм җирләү өчен кирәкле башка әйберләрне бирү һәм китерү. | 3711,86 |
| 4. Мәрхүмнең гәүдәсен (калдыкларын) зиратка күчерү | 1151,65 |
| 5. Җирләү (каберләрне казу һәм күмү) | 4308,44 |
| **БАРЛЫГЫ:** | **9678,63** |

Татарстан Республикасы
Теләче муниципаль районы
Башкарма комитетының
«31» 01 2026 ел № 10
карарына 3 номерлы кушымта

2026 елның 1 февраленнән Теләче муниципаль районында,
авыл җирлекләрен дә кертеп, җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән
исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр бәясе

| № т/б | Муниципаль берәмлек, авыл җирлекләре исеме | Җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге бәясе (сум) |
|---|---|---|
| 1. | Әбде авыл җирлеге | 9678,63 |
| 2. | Алан авыл җирлеге | |
| 3. | Айдар авыл җирлеге | |
| 4. | Баландыш авыл җирлеге | |
| 5. | Олы Мәтәскә авыл җирлеге | |
| 6. | Олы Нырсы авыл җирлеге | |
| 7. | Олы Мишә авыл җирлеге | |
| 8. | Кече Кибәхуҗа авыл җирлеге | |
| 9. | Югары Кибәхуҗа авыл җирлеге | |
| 10. | Үзәк авыл җирлеге | |
| 11. | Шәдке авыл җирлеге | |
| 12. | Иске Җөри авыл җирлеге | |
| 13. | Теләче авыл җирлеге | |